УДК: 821.512.145

*И.К. Заһидуллин*

# САНКТ-ПЕТЕРБУРГТА ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕ ҺӘМ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Статья посвящена поездке знаменитого татарского поэта и публициста, общественного деятеля Габдуллы Тукая в город Санкт-Петербург (20 апреля – 6 мая 1912 г.). Дается краткая характеристика татарскому обществу столицы, известным личностям, сыгравшим большую роль в его становлении и развитии. Рассматриваются малоизвестные факты из жизни, круг общения Г. Тукая в Санкт-Петербурге, сделана попытка обобщающей оценки данного периода жизни и творчества поэта.

**Ключевые слова:** татарская литература, Габдулла Тукай, М. Бигиев, Санкт-Петербург, татарская городская махалля, возрождение нач. XX века

The article is devoted to the trip of the famous Tatar poet and publicist, public figure Gabdulla Tukai to St. Petersburg (April 20 – May 6, 1912). A brief description is given of the Tatar society of the capital, famous personalities who played a major role in its formation and development. Little-known facts from the life and social circle of G. Tukai in St. Petersburg are considered, and an attempt is made to generalize the assessment of this period of the poet's life and work.

**Keywords:** Tatar literature, Gabdulla Tukai, M. Bigiev, St. Petersburg, Tatar city mahalla, renaissance of the beginning. The twentieth century

*(Дәвамы. Башы журналның 1 нче санында)*

## Шагыйрьнең башкалада аралашу даирәсе

1912 елның 20 апрелендә иртәнге сигездә Мәскәүдән килгән поезддан төшкән Г. Тукай, каршы алучы күренмәгәч, извозчик яллап, М. Бигиев фатирына үзе килә. Күрәсең, Г. Тукай аннан үзе өчен алдан тәгаенләнгән, М. Бигиев элегрәк хатында хәбәр иткән тукталу урынының адресын ачыкларга уйлагандыр. Шагыйрь 19 апрель көнне төштән соң Мәскәүдән җибәргән телеграмма, ниндидер сәбәпләр белән, адресатка барып ирешмәгән, шуңа күрә кунакханә мәсьәләсе дә хәл ителмәгән булгандыр. (М. Бигиев әйтүенчә, Г. Тукай үзенең килү вакытын әйтеп телеграмма җибәрмәгән, шуңа күрә ул аны вокзалда каршы алмаган.) Кунакчыл хуҗа буларак, М. Бигиев, өенә килеп кергән кунакны алдан килешенгән кунакханәгә чыгарып җибәрү матур булмас дип, Г. Тукайга үз йортының иң зур бүлмәсендә – эш кабинетында – урнашырга тәкъдим итә [28: 204].

Санкт-Петербургта Муса үзенең Чистай шәһәреннән күченгән зур гаиләсе белән яши. Фатирны еш алыштыра. Г. Тукай килгән вакытта Сергиевская урамы, 81 йорт адресы буенча 4–5 бүлмәле фатирны арендалап тора. Таврия сарае янәшәсендә урнашкан бу йорт

шәһәр үзәгеннән шактый ерак була. Фатирда, җәмәгате Әсма ханым-нан[1] тыш, кече яшьтәге 5 баласы: Мөхәммәт, Әхмәт, Һинд, Мәрьям һәм Зәйнәп [33: 52–53], шулай ук 1911 елны Югары (Бестужев) хатын-кызлар курсларына укырга кергән Өммегөлсем Камалова яши.

Күрәсең, Г. Тукай килгән көнне М. Бигиев аны шәһәр күрсәтергә алып чыккан. Атлы транспортның күп булуы белән аерылып торган Невский проспектында шагыйрь чын-чынлап куркып кала. Бу көнне алар Мөселман хәйрия җәмгыятенең рус-татар мәктәбе мөдире Лотфулла Исхаков фатирында булалар [6: 627]. Җәмгыять бинасында җомга намазлары уздырудан читләштерелгәннән соң, Л. Исхаков мөселман-прогрессистлар гаиләләрендә дини йолалар үтәү белән шөгыльләнә.

Беренче тапкыр бергәләп шәһәргә чыгу М. Бигиевкә кыска гына араны да авырлык белән узган шагыйрьнең физик халәтен ачык күрсәтә. Шуның белән башкаланың күренекле урыннарында йөртү мәсьәләсе үзеннән-үзе көн тәртибеннән төшеп кала. М. Бигиевнең гаять мәшгуль булуын исәпкә алганда, шәһәр буйлап экскурсияләрне Л. Исхаков та оештыра алган булыр иде. Әмма Г. Тукайга болай чыгып йөрүләр бик авыр икәнлеге ачыклана. Бигиев фатирында булган шәхесләрнең шагыйрьнең физик хәле турындагы гомуми фикерен, Бәкер белән очрашкач, Л. Исхаков белдерә: «Үзе авыру, хәл эчендә ята, беркайда чыга алмый, беткән инде бичара, чак җаны да, чак җүне» [9: 636]. Шагыйрь үзе дә, авыруына башкаладагы юеш һәм салкын һава килешмәгәнлектән, Дәүләт думасы утырган Таврия сараен да күрми калуы, Финляндиягә чакыруны да кабул итә алмавы, театрлар һәм музейлар белән хозурлану да мөмкин булмау, гомумән, башкала белән танышудан мәхрүм калуы турында яза [37: 179, 180].

М. Бигиев фатирында дүртенче һәм бишенче көнне [9: 656] Г. Тукай элегрәк таныш булмаган берничә кеше белән күрешә. Л. Исхаков аның янына һәр көнне килә. Шулай ук сәүдәгәр Мөхәммәдгалим Максудов[2] үзенең улы, Төркиядә укып чыккан Кәрим белән бергәләп аның янында утырып китә. Яшь егетнең Төркия турында хисләнеп, канатланып сөйләве, аның төрек әдәбиятын һәм күбесе

---

[1] Әсма (1892–1979) – Чистай шәһәре ахуны Закир ишан Камалов кызы [28: 205].

[2] Мөхәммәдгалим Максудов – Тамбов губернасы Цыпляково авылында туган. 1870 елларны Санкт-Петербургка күченә, сугым эшенә керешеп китә, ит сату лавкасы һәм сабын кайнату предприятиесе тота. 1880 елны сугым белән шөгыльләнүче А.-М. Якушевның кызы Бибихәдичәгә өйләнә. 1890 еллардан авыр йөк ташу промыселына кереп китә. Сәүдәгәр Максудов – башкаладагы хәйрия җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы, 1904–1917 елларны – аның казначысы, 1906–1913 тә – Санкт-Петербургта Мәчет төзү комитеты әгъзасы. 1906 елның гыйнварында аның фатирында мөселманнарның II Бөтенроссия съезды уза. 1914 елны яраланган солдатларга ярдәм итү өчен оештырылган мөселман иҗтимагый оешмасы Үзәк комитетында. 1914 елны типография сатып ала, ул «Максутовның "Әманәт" товариществосы типографиясе» дип атала; 1914–1916 елларны гомуми тиражы 84 мең данә булган 25 китап нәшер итә [10: 262–263; 10: 125].

хакында Г. Тукай ишетмәгән төрек шагыйрьләрен мактавы кунакның кәефен төшерә. Ул Пушкин һәм Лермонтов иҗат иткән илдә төрек шагыйрьләренә мәдхия җырлауны дөрес дип тапмый. Төрек шагыйрьләренең исемнәрен төгәлләштерү максатыннан дип, Г. Тукай егеткә сорау бирә: алар арасында Пушкин яки Лермонтов дәрәҗәсенә лаеклар бармы, юкмы? Җавап итеп яшь егет унлап шагыйрьнең исемен атый, шуның белән Г. Тукайның кәефен бөтенләй кыра. Ул, башын юләргә салып, бер үк сорауларны кабатлый башлый. Бөек шагыйрь каршында үзен имтиханда кебек хис иткән яшь кеше тулы итеп җавап бирергә тырыша. Башта улының җавапларын сокланып тыңлаган М. Максудов Г. Тукай сорауларында сатирик ноталарны тотып ала һәм, фатир хуҗасы өйдә булмауны сылтау итеп, китеп бара. Соңрак Г. Тукай Петербург мөселман җәмгыятенең абруйлы шәхесләреннән берсе белән аралашканлыгын ишетә. Аның мондый шәрехләвен үзенең ихтирамсыз тәртибе өчен гафу үтенү кебек тә кабул итәргә мөмкин [9: 639].

Бишенче көнне М. Бигиев фатирына югары уку йортларында белем алучы бер төркем татар курсисткалары килә. Г. Тукай аларны, ял итү сылтавы белән, кабул итүдән баш тарта. Әмма Кәбир Бәкер һәм Кәрим Сәгыйтов белән килгәч, татар студент егетләре белән аралашудан качып котыла алмый [9: 637–638].

Юлга чыгар алдыннан Г. Тукай үзенең танышларыннан кемнәр башкалада яшәгәнлекне белешә. Санкт-Петербургка килүгә, «Нур» газетасы редакциясенең адресын сорый һәм Ф. Әмирханның якын дусты, шушы вакытлы матбугат органында җаваплы сәркатип булып эшләгән Кәбир Бәкер, шулай ук Казанда вакытта танышкан Кәрим Сәгыйть һәм Шакир Мөхәммәдьяров белән күрешү теләген белдерә [9: 642, 651; 43: 126]. Әмма М. Бигиев тә, башкалар да газета редакциясе адресын, ул кешеләрне белмибез, дип җавап бирәләр [37: 178]. Дөрес, Л. Исхаков бу хәлләрдән хәбәрдар булып, К. Бәкерне эзләп таба һәм аның Г. Тукай белән очрашуын да оештыра. Бу вакытка инде башкаланың татар иҗтимагый эшлеклеләре арасында шагыйрьнең килүе турында хәбәр таралган була [2: 636]. Соңыннан, Бәкер белән аралашкач һәм Санкт-Петербургта татар иҗтимагый эшлеклеләренең ике оппозицион лагере барлыкны белгәч кенә, Г. Тукай бу хәлнең асыл сәбәбенә төшенә.

Шушы көннән башлап К. Бәкер Г. Тукай яныннан китми, аңа уңайлы шартлар тудыруны һәм замандашлары, киләчәк буыннар өчен шагыйрь белән аралашуларын теркәп калдыруны үзенә йөкләнгән олы миссия кебек кабул итә.

Ялгыз яшәүгә һәм Казандагы кунакханә номерларында ирегетләр белән аралашуга ияләшкән шагыйрь М. Бигиев фатирында үзен уңайсыз сизә. Фатир зур булса да, сигез кеше яшәгәнгә, кысан булып чыга. Өйләнмәгән Тукайны бигрәк тә хатын-кызлар: Мусаның хатыны Әсма ханым һәм шагыйрь исемен белмәгән курсистка (Әсманың сеңелесе Өммегөлсем) булу уңайсызландыра. Күрәсең,

курсистканың дус кызлары да кунакка килә. Кухня һәм бүлмәләрнең берсе аша юыну бүлмәсенә барганда алар белән очрашып, Г. Тукай үзен кыен хәлдә сизә, әмма, этикет саклап, исәнләшә һәм көнкүреш темаларына сөйләшергә мәҗбүр була. Әйтергә кирәк, шагыйрь хатын-кызлар белән аралашудан кача, аның якыннары әлеге сәерлегеннән хәбәрдар булалар. Ул үзен белемле һәм зыялы курсистка алдында аеруча киеренке тота [9: 637–638].

Әсма ханым, күрәсең, зур кунак өчен кулыннан килгән кадәр уңайлыклар тудырырга һәм аңа комачауламаска теләп, балаларны янына кертми. Бәлки, кунакның бүлмәдә даими рәвештә эчөзгеч ютәлләүләре һәм тәмәке тартуы [9: 642; 29: 117] да яшь ананы шикләндергәндер. Ул Г. Тукайга ашарга иренең кабинетына китерә, шагыйрьнең үтенече буенча, чәй өстәлен дә шунда әзерли. Бигиев фатирындагы ашау-эчүдән Тукай һич тә зарланмый. Күрәсең, аны тукландыру М. Бигиевнең 1914 елда Ф. Кәримигә язган хатында тасвирлаган схема буенча оештырылган булгандыр.

Шагыйрьне уңайсызландырган тагын бер хәл – фатир хуҗасының аңа зурлап эндәшүе. Күрәсең, М. Бигиев үзенең шагыйрьгә тирән хөрмәтен һәм ихтирамын ассызыкларга теләгән. Гади-гадәти аралашуга күнеккән Г. Тукай башта гаҗәпләнә, аннары мондый сөйләшү манерасыннан авырсына башлый. Ул үзе шул сәбәпле М. Бигиев белән ихлас һәм ачыктан-ачык аралашу мөмкин булмады дип саный. Югыйсә фатир хуҗасы, кунакка кыен булмасын дип, кабинетында пальтосын ябынып идәнгә ятып йоклый.

Моннан тыш, Г. Тукайның башкалага килүе М. Бигиев актив фәнни-тикшеренү эше алып барган вакытка туры килә. Ул һәр көнне озак вакытка өйдән чыгып китә, галимнәрнең лекцияләрен тыңлый. Бәлки, алар белән аралашканда Коръәннең аерым сүз-гыйбарәләренең мәгънәсен төгәлләштергәндер: чөнки аның тәрҗемәсе тәмамланып килә. Өйгә кайткач, М. Бигиев тиз генә ашап-эчеп, эш арасында гына кече яшьтәге балаларын иркәләп, беренче мөмкинлек булуга, китап тотып утыра. Шулай итеп, бер яктан, фатир хуҗасы кунак белән бик аз вакыт – иртән китапханәгә киткәнче һәм кич аралашып ала, икенче яктан, бу аралашу ихлас якынаю мөмкинлеге бирми. Моның сәбәбен Кәрим Сәгыйть Г. Тукайның күнегелгән яшәү рәвеше, буйдак мохите һәм Казан иҗат интеллигенциясенең үз-үзен тоту стереотиплары белән аңлата [29: 117].

Шагыйрьнең башкаладагы дүртенче көнендә аның янына әманәт тапшырырга җибәрелгән студент – яшь татар егете килә[1], М. Бигиев

[1] Шәриф Әхмәт улы Манатов – Оренбург губернасы Манат авылында туа. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә, 1910 елны Сәмәй укытучылар семинариясен тәмамлый. 1911 елны Психоневрология институтының педагогика факультетына «Гомуми тарих» белгечлеге буенча укырга керә. Шәхси дәресләр бирү һәм газета мәкаләләренә гонорарлар хисабына яши. 1914 елны 3 курстан укуын ташлый. Уфа газетасында басылган мәкаләсе өчен кулга алына, Швейцариягә кача. Башкорт милли хәрәкәтенең күренекле вәкиле; совет дәүләт эшлеклесе [25: 44–45].

барында аңа Мөхәммәтсафа Баязитовның визиткасын бирә [9: 641], икенче көнгә кунакка чакыра. Әмма фатир хуҗасы кискен тон белән башка кешеләргә кунакка чакырылганлыкларын әйтә. Моның чынбарлыкка туры килмәве, фатир хуҗасының үзен сүздән мәхрүм итүе шагыйрьне рәнҗетә, һәм ул, чакыручының кем икәнен белмәсә дә, һичшиксез кунакка киләчәген әйтә [9: 641]. М. Бигиев әлеге вакыйганы бераз башкачарак аңлата[1].

Бишенче көнне К. Бәкер, кунак этикасын саклап, М. Бигиевтә кунарга, иртән фатирдан китәргә тәкъдим итсә дә, Г. Тукай К. Бәкер бүлмәсендә кала. Бераздан аларга Ш. Мөхәммәдьяров[2] кушыла, студенттагы позитив кәеф башкаларга да тәэсир итә. Шундый ук күтәренке рухлы сөйләшү берничә яшь иптәшләре белән К. Сәгыйть килгәч тә дәвам итә. Аннары аралашу шәһәрдәге иң яхшы рестораннарның берсенә күчә: татар яшьләре шагыйрьне шунда чакыралар. Рестораннан соң шагыйрь төнне К. Бәкернең вакытлыча тору бүлмәсендә уздыра, ул Г. Тукайны тагын бер атна кунак итәргә һәм аңа башкаланың матур урыннарын күрсәтергә исәпли. Аның бу фатирда тагын бер бүлмә арендалау уе Г. Тукай өчен мөмкин булып чыкмый: төнге кунакның озаклап тилмереп йөткерүләрен ишеткән фатир хуҗабикәсе өстәмә бүлмә бирүдән баш тарта [9: 643–645].

Икенче көнне, «Нур» газетасы редакторы М. Баязитовның[3] чакыруы буенча, Г. Тукай аның фатирына (Мойка урамы, 22 йорт) кунакка

---

[1] М. Бигиев болай дип яза: «Мөхтәрәм Сафа хәзрәтнең бер наборщигы килүб, Габдулла әфәндене дәгъвәт итмеш. Бән у вакыт ханәмдә юк идем. Кайтдым, Габдулла әфәнде дәгъвәт хәбәрене сөйләде. “Наборщик васыйтасы илә (аша, ярдәме белән) дәгъвәт итдермәк сезең шаэнеңезә (дәрәҗәгезгә) мөкасиб дәгел (туры килми). Үзләре килүб сезе зийарәт итсүнләр (килеп күрсеннәр). Соңра дәгъвәтләренә, әлбәттә, иҗабәт (уңай җавап бирү) идерсез”, – дидем. “Капу ачык. Бәне яратмасалар, бән хәнәдә булмам”, – дидем. Ходай шаһид, бөтен сүзем шу[л]дыр» [28: 204].

[2] Шакир Зариф улы Мөхәммәдьяров (1883–1967) Орск шәһәрендә мещан гаиләсендә туа, 1905–1907 еллар революцион хәрәкәтендә катнаша, Оренбург эсерлары төркеменә керә. 1909–1913 елларда Санкт-Петербург университетының хокук факультеты студенты. 1915 елны, имтиханнар тапшырып, Мәскәү университетында юрист дипломы ала. I Бөтенроссия съездында катнаша (Мәскәү, 1917 елның мае). 1920–1930 елларда адвокатлык һәм укытучылык белән шөгыльләнә [21: 159].

[3] Мөхәммәтсафа Баязитов 1877 елның 12 декабрендә Гатаулла Баязитов (1846–1911) һәм Бибигазизә Сәйфелмөлек мулла кызы гаиләсендә туа. Гаиләдә тагын өч кыз бала үсә: Бибимәхфузә (1873), Бибизаһидә (1880) һәм Бибифатыйма (1884). Гатаулланың ике кызы, үсеп җиткәч, Сембер фабрикантлары бертуган Акчуриннарга тормышка чыга, шул рәвешле Баязитов татар дөньясының мәшһүр байлары белән туганлаша [45: 30].

Гатаулла хәзрәт Кышкы сарайга якын гына Мойка урамындагы 22 йортның 28 фатирында яши. Фатирның бер бүлмәсендә Касыйм татарлары җомга намазына җыела торган булган. Мөхәммәтсафа шул намазларда катнашып, дин кардәшләре белән аралашып үскән.

Мөхәммәтсафа башлангыч белемне Касыйм шәһәрендә туплый, дини белемне Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә үзләштерә. 1901 елны Мәхкәмәи шәргыйдә

килә. Бу йорт 2 нче мәхәллә карамагында була. Шунда ук газета редакциясе дә эшли. Дусларча көндезге аш вакытында шагыйрь, шәһәрдән китү уен үзгәртеп, К. Бәкер һәм М. Баязитовның тагын бер атна кунак булу тәкъдимен кабул итә, докторга күренергә ризалык бирә. Аны урнаштыру өчен, газета редакторы К. Бәкергә акча бирә.

Извозчик яллап, берничә кунакханәдә булганнан соң, шагыйрь шәһәр уртасындагы, Невский проспектыннан өч йорт аша гына торган, мебельле бүлмәләре булган «Казанның биш номеры» кунакханәсенә урнаша. Шуннан соң К. Бәкер һәм Г. Тукай М. Бигиевкә китәләр, әмма хуҗа өйдә булып чыкмый. Г. Тукай үзенең шәхси әйберләрен ала, кунакчыллык өчен рәхмәт әйтеп хат калдыра, үзенең яңа адресын да күрсәтә.

Кунакханәгә урнашканнан соң, Г. Тукайның Санкт-Петербургтагы тормышында яңа этап башлана.

Беренче ике көндә М. Баязитов Г. Тукайны көндезге ашка Мойка урамындагы фатирга чакыра. Әмма шагыйрь үзенә даими игътибардан борчыла башлый һәм, атлы транспорт тиз йөргәнгә, Невский проспектын чыгу уңайсыз дигән сылтау табып, бүлмәсенә каршы урнашкан ресторанда ашый башлый.

1903 елны өйләнгәннән соң, Мөхәммәтсафа Шестая Рождественская урамындагы 7 йортта фатир арендалап тора башлый. Көннәрнең берсендә ул шагыйрьне һәм К. Бәкерне гаиләсенә кунакка чакыра. Газета редакторының хатыны Зөләйха көндезге аш өстәлен

---

имтиханны уңышлы тапшырып, имам-хатыйп дини дәрәҗәсенә ия була. Шушы вакыттан башлап фатирлары каршында урнашкан мәдрәсәдә укыта [45: 58].

Мөхәммәтсафа 1900–1903 елларда Я.Г. Гуревичның шәхси гимназиясендә русча укый. Санкт-Петербург университеты Көнчыгыш факультетының француз-төрек бүлегенә укырга керә, ләкин сигез семестр укуына карамастан, бер имтихан да бирми: аны вакытында акча түләмәгән өчен имтиханга кертмәгәннәр, акча түләгәч, кабат укырга алганнар. 1911 елны этисе Гатаулла ахун вафат булгач, ул университетта укуын калдыра [38: 36].

Егет 1903 елның август аенда I гильдия сәүдәгәр Рәхмәтулла Халитовның кызы Зөләйхага өйләнә. Рәхмәтулла Халитов башкалада иң зур татар байларының берсе булып, аның Яңа авылдагы «Сәмәрканд» ресторанында чегән хорын тыңлаган Л. Толстой, Ф. Достоевский тәэсирләрен язып, рус укучысына танылa. Кызы Зөләйха, өй шартларында репетиторлар белән шөгыльләнеп, гимназия аттестаты, музыка буенча төпле белем ала, чит телләр үзләштерә. Өйләнгәч, Мөхәммәтсафаның матди хәле яхшыра. Рәхмәтулла бай арендага биреп табыш китерә торган берничә йортын яраткан кызына бирнә итеп бирә [45: 10, 33, 38, 40; 35: 147]. Яшь гаиләдә бер-бер артлы балалар дөньяга килә: Ләйлә (17.06.1904–1924), Вәлидә (19.04.1906–1994), Сара (2.08.1910–1959), Искәндәр (2.08.1910–1970). Төпчек улы Мөхәммәтсәид (1916–1986) Уфада мөфти булып эшләгән вакытта туа [38: 36; 45: 15, 70].

Беренче рус революциясе алдыннан Баязитов башкаланың мөселманнар укыган хәрби уку йортларында ислам дине нигезләреннән белем бирә, аннан Тышкы эшләр министрлыгы Азия департаментында тәрҗемәче булып эшли башлый [39: 105–130].

Гатаулла ахун күләгәсендә йөргән Мөхәммәтсафа, этисе вафатыннан соң 1911 елның 12 июнендә 2 нче мәхәллә имам-хатыйбы һәм мөдәррисе итеп билгеләнгәч, иҗтимагый чараларда ешрак күренә башлый. 1912 елның 27 апрелендә ахун исеменә лаек була. 1915–1917 елларда Оренбург мөфтие вазифасын башкара [32: 32–37].

зур җаваплылык тоеп һәм ихтирам күрсәтеп әзерли, һәр кеше алдына бик матур кызыл роза чәчәге куя – моңа һәркем игътибар итә, һәм гаять үзенчәлекле ризыклар пешерә. Ашар алдыннан кунаклар залда А. Пушкин һәм М. Лермонтов шигырьләре язылган пластинкалар тыңлыйлар. Кунакның Лермонтов «Демон»ына исе китмәгәнне күреп, хуҗа «Евгений Онегин» операсыннан арияләр язылган пластинкалар уйната. Барысын шаккаттырып, Г. Тукай беркайчан да операда булмавы турында әйтә [37: 180]. Җавап итеп, иң якын арада «Евгений Онегин» операсына бару тәкъдиме яңгырый. Ул өч көннән соң булырга тиеш икән. Г. Тукай, игътибар үзәгендә калырга теләмичә, тамашачылар залы партерының беренче рәтенә билеттан баш тарта. Шуңа күрә телефон аша «Халыклар йорты»на шалтыратып, икенче рәткә билетларга заказ бирәләр. Әмма тамаша булган көнне шәһәрдә һава торышы кисәк начарланып, көчле яңгырдан соң нык суытып җибәрә. Юештән Г. Тукайда бизгәк башлана. Бары тик мичкә ягып, өйне җылыткач кына, кичке 9 ларда Г. Тукайның хәле яхшыра.

Шуннан соң шагыйрь табибка барырга ризалаша. Ш. Мөхәммәдьяров ярдәм итәргә алына һәм университеттан үзенең таныш докторы А.Р. Польне чакыра. Доктор авыруның кем булуы хакында хәбәрдар булып, пациентка ихтирам һәм игътибар күрсәтә. Караганнан соң, аңа чын диагнозын әйтми, яхшы санаторийларның берсендә сыйфатлы дәвалау узган очракта, аның хәлсезләнгән организмы һичшиксез тернәкләнәчәк дип белдерә. Шагыйрьнең кымыз эчеп дәвалану хакындагы соравына да уңай җавап бирә, әмма дәвалану өчен уңайлыклары булган урынга барырга киңәш итә. Г. Тукайның самими балаларча сораулары табибның күңеленә тия, ул авыруны ихластан җәлли. Шуңа да А.Р. Поль үз хезмәте өчен акча алудан баш тарта һәм шагыйрьне озата килгән Ш. Мөхәммәдьяровка пациентның сәламәтлеге хакында чынбарлыктагы хәлне аңлата. Г. Тукайда туберкулёзның соңгы стадиясе булып, XX гасыр башында ул дәвалап булмый торган чирләрдән санала. Шагыйрьнең сулыш органнарының дүрттән бере генә эшли: бер үпкәсе тулысынча таркалган, икенчесенең яртысы бозык. Моның хакында белгәч, Бәкер һәм аның иптәшләре шагыйрьне Швейцариядәге иң яхшы санаторийларның берсенә җибәрергә, моның өчен үзара акча җыешырга килешәләр.

Әмма табибның үзендә башка авырулар булмау турындагы сүзләре белән канатланган һәм хәлсезләнгән организмын җиңел генә кымыз белән дәваларга ниятләгән Г. Тукай чит илдә дәвалану тәкъдимен кире кага, Санкт-Петербургтан Троицкига кымыз эчәргә китәргә дигән карарга килә, көзгә Казанга сау-сәламәт кеше булып кайтам, дип ышандыра... [9: 651–653].

Шатлыктан Г. Тукай үзенең Уфада язылган һәм иске пиджагының кесәсендә калган берничә шигырен «Нур» газетасына басарга бирә. Әмма кулъязмалар, ахыр чиктә, басылмыйча кала, чөнки газета редакциясенең идеологик юнәлешенә туры килми. Аерым алганда,

«Дин вә гавам» дигән шигырендә автор руханиларны «каргалар» дип атый.

Кунакханәдә берничә көн кунгач, прогрессистлар курьерлар аша Г. Тукайны кунакка чакыра башлыйлар. Әмма Г. Тукай, Санкт-Петербургка кунакка килмәдем һәм бу хакта берәүгә дә вәгъдә бирмәдем дигән сылтау белән, барысыннан да баш тарта. Көннәрнең берендә, К. Бәкер «Нур» газетасы редакциясенә киткәч, Л. Исхаков шагыйрьне элегрәк М. Бигиев аша чакырылган бай «Мирза әфәндегә» (аның исеме Санкт-Петербургка чакыруда да була; бу шәхес Г. Тукайның М. Бигиев фатирында ашау-эчү чыгымнарын үз өстенә алган сәүдәгәр Мөхәммәтгалим Максутовка охшап тора, чөнки Бәкер аның турында «баласын Төркиядә укытып кайтарган шәхес» дип яза) кунакка барырга күндерергә дип килә. Г. Исхаковның үгетләүләренә һәм чакыручының бүләк бирергә теләге булуы хакында әйтелүгә карамастан, Г. Тукай баш тарта [9: 655]. Көннәрнең берендә М. Бигиев тә килеп, аның хәл-әхвәлен белешеп китә [29: 118].

Бәкер һәм аның иптәшләре кунакка боегырга ирек бирми: алар Г. Тукай янына укучы яшьләрнең, мөгаллимнәрнең, аның танышларының килеп йөрүен оештыралар. Шагыйрь үзе бу хакта, бераз арттырып, бүлмәсенең чирек сәгатьтән артык кешедән бушап тормаганлыгы турында яза [37: 178].

Г. Тукай үзе берничә тапкыр «Нур» газетасы редакциясенә бара, килгән хатларны аралауда катнаша. Аерым алганда, ул Казан имамы Садыйк Рахманколыйның М. Бигиевнең «Вакыт» газетасында басылган язмасын тәнкыйтьләгән мәкаләсен бастыруны хуплап чыга. К. Бәкер бу мәкаләне йомшак дип бәяләгән була, М. Баязитов исә, аны бастыру үзара шәхси мөнәсәбәтләрдәге киеренкелекне тагын да арттырыр дип борчыла. Шулай булса да Г. Тукай, материалның йомшак булуын исәпкә алып, үзеннән берничә җөмлә өсти һәм текстны бастырырга тәкъдим итә. Дөрес, бу материал барыбер дөньяга чыкмый. Икенче юлы Г. Тукай каләм сынаучы Хәбибрахман Әлмөхәммәтовның элегрәк редакция тарафыннан йомшак һәм яңалыгы юк дип кире кагылган шигырьләрен төзәтә. Үзенең төзәтмәләре белән Г. Тукай бер төркем шигырьләрне басарга җибәрә, бу карарын киләчәк буыннарның безнең халкыбыз тарихындагы кара көннәр, каләм әһелләренең пессимизм белән сугарылган, тормышның яхшырачагына өметсезлек хакында сөйләгән шигырьләр язарга мәҗбүр булуы хакында да белергә тиешлегенә бәйләп аңлата [9: 657–658].

Яңа санга материаллар җитмәгәнлекне күреп, Г. Тукай кулына кайчы ала һәм татар газеталарыннан җирле яңалыкларны кисеп алып, бергә туплый, бу юлны «Нур» газетасын татар дөньясы яңалыклары белән тулыландыру өчен файдаланырга киңәш итә [37: 176].

10 көн кунакханәдә яшәгәннән соң, Санкт-Петербургта һава торышы һаман рәтләнергә җыенмаганлыкны күреп, һәм бигрәк тә доктор Польнең сүзләренә колак салып, Г. Тукай шәһәрдән китәргә була. Алдагы көнне М. Баязитовның Мойка урамындагы фатирында

иртәнге ашны ашагач, хуҗа кунакка фатир белән янәшә урнашкан мәхәллә мәктәбендә укучылар белән очрашырга тәкъдим итә. Г. Тукай мәктәп бинасына барып җитә, әмма очрашудан баш тарта. Шагыйрь буш бүлмәгә керүгә, мөгаллим малайлардан «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә» шигырен укуларын сорый, аннары кызлар хор белән аның «Тәэссер» һәм «Туган тел» шигырьләрен сөйлиләр. Китәсе көнне Г. Тукай номерына мәхәллә мәктәбеннән ике малайдан, өч кыздан һәм мөгаллим Мәхмүт Сипаевтан торган депутация килә. Кызлар гаҗәеп гүзәл чәчәк букеты, малайлар – шагыйрьнең күңеленә хуш килгән кыйммәтле һәм матур кара савыты бүләк итәләр [9: 658–659].

К. Сәгыйть истәлекләренә караганда, Г. Тукайны М. Баязитов төркеменең үз канаты астына алуы М. Бигиев тарафыннан авыр кабул ителә. Муса әфәнде татар байларыннан Г. Тукайны шәһәр хастаханәләренең берсенә дәваланырга салуларын, шулай халык шагыйренә ихтирам белдерүләрен сораган була. Әмма бу эш барып чыкмый. Бәлки, шагыйрьнең кунакка чакырулардан баш тартуы да бу очракта тискәре роль уйнагандыр. М. Бигиев инициативасы белән [29: 118] прогрессистлар лагеры вәкилләре шәһәрнең иң эре зиратларының берсендә хезмәткәр булган Мөхәммәдшаһ Җиһаншин фатирында Санкт-Петербургка татар шагыйре килү хөрмәтенә мәҗлес оралар. Анда 30–40 лап сәүдәгәр һәм приказчиклар, кайберләре элегрәк Г. Тукайны кунакка чакырган кешеләр җыйнала. Зыялылардан бәйрәмдә Ш. Мөхәммәдьяров, К. Сәгыйть, шәһәрнең берничә мөгаллиме, М. Бигиев һәм Л. Исхаков катнаша. Мәҗлес ахырында Г. Тукайга эчендә конвертка салынган 50 сум акча да булган адрес тапшырыла [9: 669]. К. Сәгыйть истәлекләре буенча, каршы лагерьныкылар Г. Тукайга чакыруны кабул итмәскә киңәш бирә, аны курьер аша түгел, Л. Исхаков һәм М. Бигиев шәхсән чакырырга тиешләр иде, дип әйтәләр… [29: 118].

Поезд Мәскәүгә расписание буенча 6 майда [37: 374, 378] төнге беренче яртыда кузгала. Шагыйрьне озатырга Николаев вокзалына М. Баязитов, Л. Исхаков, укучы яшьләр, приказчиклар – якынча 20–30 кеше җыйнала. Кызганычка каршы, шагыйрьгә Санкт-Петербургтан Уфага кадәр билет алып бирергә вәгъдә иткән М. Бигиев озатырга төшми. Күрәсең, ул каршы лагерь җитәкчесе белән күңелсез аралашудан алган тәэсирләрне җиңә алмагандыр[1]. Үзара киңәшеп, Баязитов һәм Бәкер үзләре билет сатып алырга булалар. Г. Тукай, үз ягыннан, ютәлем белән икенче класс пассажирларына уңайсызлык тудырырмын дип, билетны өченче классның плацкарт вагонына сорый [9: 661].

[1] 1914 елны, 1 нче мәхәллә имамы Мөхәммәтзариф Юнысов үлгәннән соң, имам вазифасы вакантлы була. М. Бигиев мәхәллә кешеләре тарафыннан мулла итеп сайлана. Әмма Эчке эшләр министрлыгы аны бу вазифада расларга теләми. А. Таһирҗанова язуынча, югары хакимиятнең мондый позициясе Муса әфәнденең шәхсән халәте белән тәңгәл килә: ул яңа мөфти Баязитов кул астында эшләүдән баш тарта [33: 103, 105, 107].

К. Бәкер Г. Тукайны Мәскәүгә кадәр озата бара. Николаев вокзалыннан бер этажлы Рязань вокзалына күчкәч[1], ул юлчыны ашата, чәй белән сыйлый, Уфага баручы поездга утыртып, аның белән җылы саубуллаша.

Исән-имин Уфага килеп җитеп, Г. Тукай М. Баязитовка һәм К. Бәкергә рәхмәт әйтеп хат җибәрә. 1912 елның 12 маенда язылган, К. Бәкергә адресланган хатында ул Ш. Мөхәммәдьяровка һәм К. Сәгыйтькә сәлам тапшыруын үтенә [9: 662].

М. Бигиевнең шагыйрьнең көнитешен һәм сәламәтлеген ихластан кайгыртып уйланган планнары, аның бу хакта мөселман-прогрессистлар лагеренең хәлле кешеләре белән алдан килешенгән эшләренең күбесе, аларның ашыкмавы һәм Казан кунагының тәкәллефсезлеге сәбәпле, тормышка ашмыйча кала.

Шулай итеп, Г. Тукайның Санкт-Петербургка сәяхәте шагыйрьнең Казаннан иң соңгы чыгып йөрүләреннән була. Шәһәрдә торган вакытының икенче өлеше, М. Баязитов һәм К. Бәкернең җылы кайгыртучанлыгы белән, аның тормышының иң яхшы мизгелләреннән берсенә әйләнә. Үзенең «Мәкаләи махсуса» язмасында, башкалага 13 көнлек сәяхәтенә йомгак ясап, Г. Тукай М. Баязитов кайгыртуында йорт җиһазлы бүлмәдә уңайлы, «күңелле һәм матур көннәр» уздыруын билгели. Бер лагерьга да кермәгән укучы яшьләр белән аралашып, ул үсеп килүче буында үз шәхесенә тирән хөрмәт һәм талантына ихтирамны күрә. Санкт-Петербургта үзе кичергән иң яхшы мизгелләр, «җан рәхәте» дип Г. Тукай М. Баязитовтагы пластинкалар тыңлаган мәҗлесне күрсәтә [37: 180, 181].

Тукай белән аралашып, К. Бәкер шагыйрьне үзе өчен өр-яңадан ача, аның шәхси фаҗигасын үз күңеле аша уздыра. Аның өчен шагыйрьнең элегрәк бу якты дөньяда яшәүдән инде туйганлыгы турында ярым шаярып, көлеп әйткән сүзләре бөтенләй башка мәгънә белән сугарыла. К. Бәкер аның сүзләренә игътибар итә, шигырьләрендә яңа интонацияләр таба башлый, аларны «юл арасыннан» укырга өйрәнә.

Санкт-Петербургтан Г. Тукай күтәренке кәеф, савыгуына зур өметләр белән кузгала, ә тирә-ягындагылар инде шагыйрьнең озаклямый якты дөнья белән бөтенләйгә хушлашасы хакында хәбәрдар була…

## Әдәбият

1. *Азаматов Д.Д.* Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII–XIX вв. Уфа: Китап, 1999. 194 с.

2. *Аминов Д.А.* Татары в Ст. Петербурге. Исторический очерк. СПб.: «Альд», 1994. 49 с.

3. *Амирханов Р.У.* Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. Казань, 1992. С. 22–60.

[1] Яңа Казан вокзалы 1913 елда гына төзелә башлый.

4. *Амирханов Р.У.* Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток – Запад» (на примере развития русской культуры). Казань, 2002. 238 с.

5. *Әмирхан Р.* Иманга тугрылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

6. *Әхмәтҗанов Шәриф.* Искә төшерү (Габдулла Тукаев Петербургта) // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 1 т. Б. 625–631.

7. *Батулла Р.* Бакир (Бакиров) Кабир // Татарская энциклопедия. Т. 1: А–В / гл. ред. М.Х.Хасанов. Казань: Ин-т Татар. энцикл., 2002. С. 283–284.

8. *Бахтияров А.А.* Брюхо Петербурга. Очерки столичной жизни. Л., 1994. 224 с.

9. *Бәкер Кәбир.* Тукай Петербургта // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 1 т. Б. 632–662.

10. *Беккин Р.* Татары в Санкт-Петербурге: конебойный промысел (XIX – начало XX в.) // Эхо веков – Гасырлар авазы. 2015. № 3/4. С. 259–264.

11. *Биктимирова Т.А.* Ступени образования до Сорбонны. Казань: Алма-лит, 2003. 184 с.

12. Высшие женские курсы (основаны в 1876 г.). Отчет за 1907–1908 г. СПб.: тип. Ю.Н. Эрлих, 1909. 75 с.

13. *Загидуллин И.К.* Исламские институты в Российской империи: Мусульманская община в Санкт-Петербурге. XVIII – начало XX вв. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2003. 179 с.

14. *Загидуллин И.К.* Мусульманское богослужение в учреждениях Российской империи (Европейская часть России и Сибирь). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2006. 462 с.

15. *Загидуллин И.К.* Национальное движение мусульман Волго-Уральского региона в начальный период революции 1905–1907 гг.: монография. Казань: ООО «Центр инновационных технологий», 2019. 256 с.

16. *Загидуллин И.К.* Татары Чистополя в петиционной кампании мусульман 1905 г. // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2024. №2. С. 14–23.

17. *Загидуллин И.К., Тагирджанова А.А.* Исхаков Лутфулла Феткуллович // Ислам в Санкт-Петербурге. Энциклопедический словарь / Коллектив авторов; сост. и отв. ред. Д.З. Хайретдинов. М.; Н. Новгород: Изд. дом «Медина», 2009. С. 96.

18. *Зәбири Хабиберахман.* Габдулла әфәнденең Уфадан Петербурга баруы // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 1 т. Б. 668–670.

19. Искәрмәләр һәм аңлатмалар // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юльязмалар, хатлар (1903–1913) / төз. һәм аңл. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 345–405.

20. Исторические кладбища Петербурга: Справочник-путеводитель / [Санкт-Петербург. фонд культуры; сост.: А.В. Кобак, Ю.М. Пирютко]. СПб.: Изд-во Чернышева, 1993. 639 с.

21. *Исхаков С.М.* Ахтямов Ибниамин Абуссугутович // Башкирская энциклопедия. Т. 1. Уфа, 2005. С. 254.

22. *Исхаков С.* Мухамедьяров Шакир Зарифович // Ислам в Санкт-Петербурге. Энциклопедический словарь / Коллектив авторов; сост. и отв. ред. Д.З. Хайретдинов. М.; Н. Новгород: Изд. дом «Медина», 2009. С. 159–160.

23. *Исхаков С.М.* Первая русская революция и мусульмане Российской империи. М.: Наука, 2007. 400 с.

24. *Каримулин А.Г.* Татарская книга пореформенной России. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 318 с.

25. Манатов Шәриф Әхмәт улы // Татар энциклопедиясе / баш мөх-р Ә.М. Мазһаров. Т. 4. М–П. Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2014. Б. 44–45.

26. Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 года. Т. XXXVII. Город С.-Петербург. Тетрадь 2 и последняя / под ред. Н.А. Тройницкого. СПб., 1903. XXXII, 261 с.

27. *Рашин А.Г.* Население России за 100 лет (1811–1913 гг.). Статистические очерки. М.: Гос. стат. изд-во, 1956. 324 с.

28. *Рәхимова А.* «Шу мәктүбем сүзләре сезә эманәтдер...» // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. № 1/2. Б. 200–205.

29. *Сәгыйдова Э. Г.* Кәрим Сәгыйд архивыннан // Казан утлары. 1968. № 4. Б. 115–119.

30. Слушательницы С.-Петербургских высших женских, Бестужевских курсов. По данным переписи (анкеты), выполн. статистическим семинарием в ноябре 1909 г. / Стат. семинарий С.-Петерб. высш. жен. курсов. СПб., 1912. XX, 144 с.

31. *Тагирджанова А.* Бигиев Муса Яруллович // Ислам в Санкт-Петербурге: Энциклопедический словарь / Коллектив авторов; сост. и отв. ред. Д.З.Хайретдинов. М.; Н. Новгород: Изд. дом «Медина», 2009. С. 37–38.

32. *Тагирджанова А.Н.* Как Министерство внутренних дел назначало оренбургского муфтия в 1915 г. // Клио. 2007. № 4 (39). С. 32–37.

33. *Тагирджанова А.* Книга о Мусе-эфенди, его времени и современниках. Сборник историко-биографических материалов. Казань, 2010. 576 с.

34. *Тагирджанова А.* Максутов Мухаммед-Алим Рахимович // Ислам в Санкт-Петербурге. Энциклопедический словарь. М., 2009. С. 125.

35. *Тагирджанова А.Н.* Мечети Петербурга: проекты, воплощение истории мусульманской общины. СПб., 2014.

36. *Тукай Г.М.* Шигырь (Шималь яктан...) // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908) / төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл.: Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 45.

37. *Тукай Г.М.* Мәкаләи махсуса // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юльязмалар, хатлар (1903–1913) / төз. һәм аңл. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 167–183.

38. *Усманова Д. М.* Баязитов Мухаммед-Сафа // Ислам в Санкт-Петербурге. Энциклопедический словарь / Коллектив авторов; сост. и отв. ред. Д.З. Хайретдинов. М.; Н. Новгород: Изд. дом «Медина», 2009. С. 35–36.

39. *Усманова Д.* Последний муфтий Российской империи // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2020. № 4. С. 105–130.

40. *Файзрахманов И.З.* Татарский след на берегах Невы: из истории строительства Санкт-Петербурга в первой четверти XVIII в. // Научный Татарстан. 2009. № 2. С. 222–233.

41. *Хайрутдинов А.Г.* Бигиев Муса // Татарская энциклопедия / гл. ред. М. Хасанов. Т. 1. А–В. Казань: Ин-т Татар. энцикл., 2002. С. 378.

42. *Шангараев Р.* Газета «Нур» как интегрирующий татарское общество в российское социокультурное пространство элемент // Вестник Казанского государственного университета культуры и исскуств. 2007. № 2. С. 90–92.

43. *Шәйхелисламов З.Р.* Бигиев Муса Яруллла улы // Габдулла Тукай. Энциклопедия. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. Б. 126–127.

44. *Юхнева Н.В.* Этнический состав и этносоциальная структура населения Петербурга, вторая половина XIX – нач. XX в. Стат. анализ / под ред. К.В. Чистова. Л.: Наука: Ленингр. отд-ние, 1984. 223 с.

45. *Янбаева Я.* Потомки Баязитова // Мусульманский мир. 2009. № 3. С. 9–70.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Исламны өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

***Загидуллин Ильдус Котдусович,***
*доктор исторических наук, доцент, старший научный сотрудник Центра исламоведческих исследований АН РТ*

*zagik63@mail.ru*